1918 елның 1 мартыннан чыга

№ 106 (25410), сишәмбе, 10 сентябрь, 2019 ел

Сатуда бәясе ирекле

Кызыл тан

Республиканың иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни басмасы

Оештыручылар: Башкортстан Республикасы Дәүләт җыелышы - Корылтай, Башкортстан Республикасы Хөкүмәте

Гәзит сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга. Интернеттагы адресыбыз: www.kiziltan.rbsmi.ru

12+

4 665299 181302 19106 >

Сайлау-2019

70+/80+!

Башкортстанлылар мөһим кампаниядә гражданлык активлыгы һәм зирәк сәяси акыл күрсәтте



8 сентябрьдә, Башкортстанда иртәнге сәгать 7дә 3434 сайлау участогы ачылды. Бердәм тавыш бирү көнендә республика халкы Башкортстан Башлыгын сайлады. Республика җитәкчесе вазыйфасына 8 кандидат дәгъва итте. Бу көнне, шулай ук, 9нчы Солнечный сайлау округы (Уфа шәһәренең Октябрь районы) һәм 16нчы Комсомол сайлау округы (Нефтекама шәһәре) буенча VI чакырылыш Дәүләт җыелышы-Корылтай депутатларын өстәмә сайлаулар, урындагы үзидарә органнарына депутатлар сайлау буенча 818 сайлау кампаниясе үтте. Аларда урындагы үзидарә вәкиллекле органнарына 7329 депутат сайланды. Бу сайлауларда 11 сәяси партиядән 14978 кандидат теркәлгән иде.

Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров Уфа шәһәренең 109нчы сайлау участогында тавыш бирде.

— Бүген Башкортстан өчен җаваплы көн, без сайлау кампаниясен оештыру буенча зур эш башкардык. Республика Башлыгын сайлаудан тыш, бүген халык 7 меңнән артык урындагы совет депутатын сайлый. Безнең бурыч — сайлау кампаниясенең үтәкүренмәле, гамәлдәге законнар нигезендә үтүен тәэмин итү. Минемчә, без моңа ирешә алдык. Тавыш бирү нәтиҗәләрен бүген төнлә беләчәкбез, — диде Радий Хәбиров.

* * *

9 сентябрьдә республика Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Илона Макаренко журналистлар өчен оештырылган матбугат конференциясендә республикада үткән Башкортстан Башлыгын сайлауларның йомгаклары белән таныштырды.

Тавыш бирүдә республика буенча — 71,80 процент, Уфа шәһәрендә — 66,15 процент, башка шәһәрләр буенча — 63,30 процент, районнарда 77,78 процент сайлаучы катнашкан. Районнар арасында иң зур күрсәткеч Тәтешле районында — 97,01 процент, Салават районында — 94,26 процент, Бакалы районында 92,78 процент сайлаучы тавыш бирүдә катнашкан. Минималь күрсәткеч Благовещен районында — 61,14 процент.

1 июльгә булган мәгълүматларга караганда, республикада 3 миллион 49 мең 571 сайлаучы теркәлгән.

“Бердәм Русия” партиясеннән кандидат, Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы **Радий Хәбиров** өчен 1 миллион 794 мең 113 сайлаучы тавыш биргән, ул — 82,02 процент тавыш җыйган.

Икенче урында — КПРФтан төбәк Башлыгы вазыйфасына кандидат **Юнир Котлыгуҗин**, аның өчен 150679 сайлаучы тавыш биргән (6,89 процент). ЛДПРдан кандидат **Иван Сухарев**ка 99158 кеше тавыш биргән (4,53 процент). “Яблоко”дан **Зөлфия Гайсина** өчен — 33371 сайлаучы (1,53 процент), “Гадел Русия”дән **Юрий Игнатьев**ка — 26935 сайлаучы (1,23 процент), “Русия патриотлары”ннан **Рәфис Кадыйров**ка — 24032 сайлаучы (1,10 процент), “Гражданлык көче”ннән **Владимир Барабаш**ка — 21175 сайлаучы (0,97 процент) һәм “Русия пенсионерлар партиясе”ннән **Владимир Кобзев**ка 17678 сайлаучы (0,81 процент) тавыш биргән.

Сайлауда республика Үзәк сайлау комиссиясе 24 мөрәҗәгать кабул иткән, шикаятьләр юк.

* * *

Бердәм тавыш бирү көне нәтиҗәләре буенча “Бердәм Русия” партиясе лидерлык позицияләрен саклый һәм илебезнең әйдәп баручы сәяси көче булып кала. Бу хакта партия рәисе, Русия Хөкүмәте Премьер-министры Дмитрий Медведев 8 сентябрьдә Мәскәүдә төбәкләр вәкилләре белән киңәшмә барышында белдерде.

— Мин хәзер ахыргы нәтиҗәләрне чыгармыйм, чөнки алар формалаша гына. Барлык сайлау участоклары да ябылган, тавышларны санау башланды. Тик безгә Ерак Көнчыгыш һәм Себердән килгән мәгълүматны, шулай ук экзит-поллар буенча ачык мәгълүматларны күздә тотып, “Бердәм Русия” партиясе үзенең лидерлык сыйфатларын саклый һәм илебезнең әйдәүче сәяси көче булып кала, дип әйтергә була. “Бердәм Русия” вәкилләре өчен тавыш бирүчеләрнең барысына да чын күңелдән рәхмәтемне җиткерәм. Без моны бик югары бәялибез. Әлбәттә, бу безгә киләчәктә дә дөрес карарлар кабул итү өчен нигез булып тора, — дип белдерде Дмитрий Медведев.

Радий Хәбиров Башкортстанда тавыш бирү нәтиҗәләре турында сөйләде. Ул шулай ук Дмитрий Медведевны сентябрь азагында Уфада узачак ШОС һәм БРИКС илләре кече бизнесының V форумында катнашырга чакырды.

Фәнүз ХӘБИБУЛЛИН.

Элена САЯПОВА инфографикасы.

СТАДИОН ДА, ШУГАЛАК ТА БУЛАЧАК

Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров Уфа буйлап эш сәфәре барышында Орджоникидзе районының социаль һәм спорт объектларында булды, территорияне үстерү перспективалары турында фикер алышты.

Төбәк җитәкчесе менталь һәм үсешендә башка җитешсезлекләр булган яшь кешеләр өчен ачылган укукыту фатирында булды. Биш көнлек курс кысаларында анда дүрт яшь егет яисә кыз яшәячәк. Алар белгечләр ярдәмендә ризык әзерләү, үз-үзеңне хезмәтләндерү, җыештыру, транспортта йөрү һәм башка күнекмәләрне үзләштерәчәк.

Радий Хәбиров “СоДействие” үзәге белгечләре һәм әлеге фатирдагы беренче балалар белән аралашты, аларның яшәү шартлары белән танышты һәм бу тәҗрибә буенча балаларның ата-аналары белән киләсе очрашуларның берсендә фикер алышырга, шәһәрнең көньяк өлешендә тагын бер шундый фатир ачу мөмкинлеген карарга тәкъдим итте.

Радий Хәбиров “Төзүче” стадионында Г. Кадыйров исемендәге Спортның техник төрләре үзәге эшчәнлеге белән танышты, спортчылар белән аралашты, техниканы карады.

(Ахыры 2нче биттә).

АВЫРУНЫ ИРТӘ АЧЫКЛАУЧЫЛАРГА – 5 МЕҢ СУМ!

Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров Уфада 13нче шәһәр клиник дәваханәсе нигезендә күчмә “Сәламәтлек сәгате” уздырды.

Сәламәтлек саклау министры вазыйфасын башкаручы Максим Забелин һәм дәваханәнең баш табибы Эльза Сыртланова учреждениедә сакчыл медицина технологиясе гамәлгә ашырылуы турында сөйләде.

Биредә пациентларны индивидуаль штрих-код һәм авыру турында өстәмә мәгълүмат тупланган махсус электрон браслет буенча идентификацияләү кертелгән. Бу дәвалау процессында хаталарны булдырмау мөмкинлеге бирә һәм шәхси мәгълүматларны саклый.

Медицина оешмасында онкология авырулары белән актив көрәшәләр. 1 июльдән биредә 13нче шәһәр дәваханәсе һәм 2нче, 38нче поликлиникаларга караган пациентларга хезмәт күрсәтүче Амбулатор онкология ярдәме үзәге эшли башлады.

Арытаба төбәк җитәкчесе табибларга онкология авыруларын иртә ачыклаган өчен бер тапкыр бирелүче акчалата түләү алуга сертификатлар тапшыру тантанасында катнашты.

– Без башлангыч стадияләрдә онкоавыруларны ачыклаганда игътибар һәм профессионализм күрсәткән табиблар һәм фельдшерларга 5 мең сум күләмендә премия түләү турында карар кабул иттек, – диде Радий Хәбиров. – Бүген сертификат алган табибларга рәхмәт белдерәсем килә. Монда мәсьәлә акчада түгел, ә безнең рәхмәтебездә, чөнки сез кешеләр гомерен саклап каласыз.

Республика бюджетында бу максатларга 30 миллион сум каралган. Шуларның 12 миллион сумы инде түләнгән, ягъни агымдагы елның җиде аенда онкоавыруларның 1 650дән артык очрагы ачыкланган.

Радий Хәбиров, кирәк булган очракта, профилактик чаралар үткәрүгә бюджет чыгымнарын арттырырга кушты.

“БАШКОРТСТАН ЛИДЕРЛАРЫ” НИНДИ ТӘКЪДИМНӘР КЕРТӘ?

“Торатау” Конгресс-холлында Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров “Башкортстан лидерлары” конкурсы финалчылары белән очрашты.

– Безнең бурыч республикага яңа энергия бирү. Әгәр без зур командага саф һава кертмәсәк, төбәкнең арытаба үсешен гамәлгә ашыру авыр. Шуңа күрә дә шундый бәйге үткәрергә булдык, – диде Радий Хәбиров. – Моннан тыш, без яшьләрдән, энергияле кешеләрдән ниндидер ышаныч кредиты алырга телибез.

Очрашуда катнашучылар төбәк җитәкчесе белән Башкортстанның социаль-икътисади үсеше мәсьәләләре турында фикер алышты. Алар арасында – инвестицияләр җәлеп итү, бизнеска ярдәм итүнең төрле инструментларын нәтиҗәле файдалану, сәламәтлек саклау системасын камилләштерү, авылга ярдәм итү, яшьләрне җәлеп итү, төрле тармакларны санлаштыру, тирә-як мохитне саклау, шәһәр төзелеше сәясәте һәм территорияләрне төзекләндерү дә бар.

Радий Хәбиров белдерүенчә, әлеге вакытта 2024 елга кадәр республика үсеше стратегиясен билгеләячәк программа документын әзерләү бара. Анда гомум трендлар гына түгел, һәр мөһим юнәлеш буенча тәгаен, үлчәмле күрсәткечләр дә билгеләнәчәк.

– Бу программа Русия Президентының май указларында куелган бурычларга, гомумдәүләт проектларына нигезләнәчәк, әмма безнең республика, муниципалитетлар эшчәнлегенә яраклаштырылачак, – диде ул.

ЮРИДИК БАТТЛДА – ОСТАЗЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘР

Уфада Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров яшь юристлар белән беренче LEGAL BATTLE конкурсында катнашты. Ул Русия Юристлар ассоциациясенең төбәк бүлеге тарафыннан оештырылды.

Эшлекле уенда Русия Юристлар ассоциациясенең Башкортстан бүлекчәсе советын, республиканың Яшь юристлар советын, ассоциациянең Тамбов бүлеген, Башкортстан прокуратурасын һәм Башкортстан буенча Федераль салым хезмәте идарәсен төкъдим итүче биш команда катнашты. Модераторлар – билгеле адвокат, Русиянең атказанган юристы Анатолий Кучерена һәм Башкорт дәүләт университетының дәүләт һәм хокук теориясе кафедрасы мөдире, юридик фәннәр докторы Гүзәл Азнагулова.

Юридик баттл законнарны белү, видеосораулар, үз позициянне дәлилләү һәм ораторлык күнекмәләрен күрсәтергә тиешле капитаннар конкурсын үз эченә алды.

Төбәк җитәкчесе Совет рәисе Андрей Назаров, Дәүләт думасы депутатлары Павел Крашенинников, Зариф Байгускаров, Рафаэль Мәрданшин, җир һәм милек мөнәсәбәтләре министры вазыйфасын башкаручы Олег Полстовалов белән бергә Русия Юристлар ассоциациясенең Башкортстан бүлекчәсе советы командасына керде. Нәкъ алар командасы баттлда җиңүче булды.

– Әлеге формат миңа кызыклы тоела. Юридик берләшмә хупласа, без бу чараны ел саен үткәрәчәкбез, – диде Радий Хәбиров. – Бу бәйге безнең өчен түгел, ә яшь укытучылар, аспирантлар, студентлар өчен. Миңа калса, аларга юриспруденция мәтрлары белән аралашу, ярышларда катнашу кызыклы булды.

Төбәк җитәкчесе Олег Полстовалловка юридик фәннәр үсешенә керткән өлеше өчен “Башкортстанның атказанган юристы” исемен тапшыру турындагы указга кул куюын хәбәр итте.

Үз хәбәрчебез.

Гәзитнең киләсе саны 13 сентябрьдә чыга.

График буенча кул кую вакыты — 15.00
Гамәлдә кул куелды — 14.50